РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

Буа шәһәре

КАРАР

№ 10-54

23 июнь 2020 ел

Буа районы Советы карарын үз көчен
югалткан дип тану турында

«Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» 2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы,2019 елның 1 мартындагы 7-ТРЗ номерлы «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрен төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында «Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлешенең үз көчен югалтуын тану хакында» Татарстан Республикасы Законнары нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе турында» 2018 елның 11 декабрендәге 5-36 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карар рәсми бастырылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адрес буенча, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адрес буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Буа муниципаль районы башлыгы урынбасары,
Совет рәисе урынбасары И.Ф. Еремеев